| ГЛАВА БОЛЬШЕКАЙБИЦКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ КАЙБЫЧ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30 сентябрь, 2019ел Олы Кайбыч авылы № 3

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Кайбыч авыл җирлегенең Афанасьевка авылында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Кайбыч авыл җирлеге Уставының 22 маддәсе нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. 2019 елның15 октябренә 14 сәгать 00 минутка Афанасьевка авылы, Контор урамы, 11 нче йорт адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Кайбыч авыл җирлегенең Афанасьевка торак пунктында үзара салым алып бару мәсьләләре буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Кайбыч авыл җирлегенең Афанасьевка авылы территориясендә даими яшәүче һәм яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

*а) җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:*

-материаллар сатып алып, урам утларын ремонтлау;

-җирлектәге торак пунктлардагы чүплекләр территорияләрен чистарту;

*б) җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру::*

- материаллар сатып алып, суүткәргеч челтәрләрен ремонтлау;

*в) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:*

- материаллар сатып алып, юлларны норматив хәлгә китерү;

- торак пункт чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту.»

« РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Кайбыч авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка таратырга һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Кайбыч авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районының
Олы Кайбыч авыл җирлеге Башлыгы А.И. Рәхмәтуллин